وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№17 (134). 27 апрель 2012 / 6-җөмәдел-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мамадыш мәдрәсәсе ▷2◁



Мөхәммәд галәйһиссәламнең үз кулыннан... ▷3◁



Ничек конфликтларсыз аралашырга? ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ОРЕНБУРГТА ОЧРАШУ УЗДЫ**

26 апрель көнне Оренбургта РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич беренче тапкыр дин әһелләре белән очрашты. Әлеге очрашуда Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз катнашты.

Чарада сүз хакимият белән мөселманнарның дини оешмалары арасындагы үзара эшчәнлекне ныгыту хакында барды. Шулай ук дин әһелләре, җитәкчеләр экстремизм кебек Россия өчен гомуми проблеманың Идел буе округында чагылышы турында да фикер алышты.

Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз бүгенге көндә Россия мөселманнары тормышында уңай алгарыш күзәтелүен билгеләп үтте. Бу бик җиңел булмаган үсештә дәүләт һәм мөселманнар арасында үзара эшчәнлек мәйданы барлыкка килү зур роль уйнаганны әйтте. "Берсүзсез, дәүләт һәм дин әһелләре арасындагы диалог тыныч яшәүнең бер нигезе булып тора. Россия күпмилләтле, күпдинле дәүләт, гәрчә кайберәүләр моны танырга теләмәсә дә. Төрле милләтләр һәм төрле дин тотучылар тату яши торган Татарстан бу уңайдан бер үрнәк мисал. Татарстан толерант исламны пропагандалый. Һәм моның өчен күп тырышлык куя. Республика җитәкчелеге халыкны яклауга, радикаль агымнардан саклауга кагылышлы дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга барлык шартларны тудыра", - диде ул.

Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкил Михаил Бабич дини лидерларга: "Бүгенге сөйләшү Идел буе округына кергән төбәкләрдә мөселманнарга, православие динендәгеләргә һәм башка конфессия вәкилләренә дә үзләренең дини эшчәнлекләрен алып бару өчен шартлар тудырылган дигән фикерне раслады. Барыбызга бер таләп - закон бозмаска", - диде.

**ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНДӘ - КАЗАКЪСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ**

26 апрель көнне Казакъстанның Актүбә өлкәсе хакиме Архимед Мөхәмбәтов җитәкчелегендәге делегация ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә булды. Казакъстан кунаклары ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Казан шәһәре казые Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдинов белән очрашты.

Очрашуда катнашучылар республиканың дини, мәдәни тормышы турында фикер алышты, үзара хезмәттәшлек итү турында сөйләште.

**ЯШҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН "БӨРКЕТ" КУРСЛАРЫ БАРА**

Мөселман яшьләре берлеге Диния нәзарәтенең "Алтын урта" клубы белән берлектә 23-29 апрель көннәрендә Казанның Мәрҗани мәчетендә яшүсмерләр өчен "Бөркет" дип исемләнгән курслар башлап җибәрде.

Әлеге чара яшүсмерләргә яхшы ир, уңышлы эшкуар һәм зирәк, акыллы, спорт яратучы мөселман кешесе булырга ярдәм итәчәк. Дәресләр программасына үтемле вәгазьләр, кызыклы тренинглар, төрле лекцияләр һәм спорт чаралары кертелгән. Белешмәләр өчен телефон: **89872121179.**

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Коръән шифасын фән дә раслый

**Бүгенге чынбарлыкта мөселман кешесе нәрсәгә омтылырга тиеш? Әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә өметләнүчеләрнең кыйммәтләре җәмгыятьтәге сәяси, икътисади, мәдәни вәзгыятьнең нинди булуына карамастан үзгәрми. Шул ук вакытта, Аллаһка ышануыбыз намазлык яки мәчет диварлары белән генә чикләнмәвен истән чыгармыйк. Мөселман кешесенең рухи һәм физик халәте, тормышы Ислам белән бөтен яклап билгеләнергә тиеш. Монда сәламәтлекнең роле бик мөһим, чөнки ул безнең Аллаһка табынуыбызның бер таянычы булып тора.**



Ныклы сәламәтлек ул - Коръәндә язылганнарны үтәп яшәвебезне дә күрсәтә. Безгә Аллаһы Тәгалә кешенең тәненә бәйле барлык әйберләрне аңлаткан: көмәнле булу, яралгы үсүе (Коръән, 11:72; 19:9; 24:31,60; 65:4); анатомик һәм физиологик үзенчәлекләр (Коръән, 7:69; 16:66; 35:1). Мәрхүмнең җәсадәсен урнаштыруга кадәр язылган (Коръән, 5:31; 80:21). Аллаһ безгә ышаныч күрсәтеп, Коръән аша тәнебезнең нормаль халәтен, икенче төрле әйткәндә, сәламәтлегебезне саклау өчен инструкция биргән.

Әмма сәламәтлек яхшы гына була алмый, чирләр дә кешенең физик халәтенең бер өлеше. Авырулар безнең түземлегебезне сынап һәм авырлыклар турында уйланырга мәҗбүр итеп тормышыбызны озата килә. Әмма физик көчсезлек белән килешү Аллаһка бик нык ышану күрсәткече дә була алмый. Аллаһ Коръән аятләре безгә шифа икәнне белдерә: "Без Коръәннән шундый хикмәт иңдерәбез ки, ул мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәттер, гаделсезләр өчен исә бары тик зыян гына китерә" ("Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары) сүрәсенең 82 нче аяте).

Коръәндә язылганнарның кешеләргә дәва булуын раслаган бик күп мисалларны китерергә мөмкин. Әйтик, Стэнфорд университеты докторы Фредерик Лускин үзенең тикшерүләре белән гафу итә алу пациентларның гомуми сәламәтлеген ныгытканны раслады. Даими стресс аркасында барлыкка килгән гипертония, ашказаны авыруларын вакытында гафу итә, кичерә белү дәваларга булыша. Коръән безгә: "Берәү хаксыз золымга сабыр итсә һәм залимне гафу да итсә, бу эш, ягъни үч алмыйча сабыр итү һәм Аллаһ ризасы өчен гафу итү, бик зур саваплы вә бик зур файдалы эштер", - дип докторлар ачыш ясаганчы ук киңәш итте.

Коръән, Аллаһы Тәгалә сүзе буларак, рухи гына түгел, ә тән авыруларыннан да иң яхшы "дару". Бүгенге көндә бик күп тикшеренүләр Коръән уку һәм аны тыңлау шифа икәнне раслады. Американың Флорида штаты клиникасы табиблары һәм доктор Әхмәт әл-Кадый үзләренең тикшеренүләре турында Истанбулда уздырылган Халыкара ислам медицинасы форумында сөйләгәннәр иде. Эксперимент вакытында сүрәләрне тыңлау йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системасы эшчәнлегенә уңай тәэсир иткәне күренгән. Сүрәләрне аңлап тыңлаганда бу уңай тәэсир тагын да нәтиҗәлерәк булган. Шуны да әйтергә кирәк, экпериментта мөселман булмаган кешеләр дә катнашкан.

Бүгенге заман фәне Коръәндә язылганнар белән азрак бәхәсләшә. Шул исәптән медицина да. Чөнки тирә-юнебезне танып белү өчен мөмкинлекләр арта, нәтиҗәдә "Аллаһ сүзе" белән дискуссиягә керү өчен сәбәпләр дә азая бара. Шулай да без Коръәннең "медицина энциклопедиясе" түгеллеген аңлыйбыз, чынлыкта ул тормышыбыз өчен бетмәс дәва-шифа табу чыганагы һәм Аллаһның зур бүләге - рухи, физик сәламәтлегебезне саклау өчен изге кулланма икәнлеген исебездән чыгармыйк.

Әлеге төшенчәләрне аңлау максатыннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Коръән елы уңаеннан медицина белгечләре һәм дин әһелләре белән берлектә "Коръән һәм сәламәтлек" дип аталган "түгәрәк өстәл" уздырырга әзерләнә. Табиблардан һәм дин әһелләреннән әлеге чарага карата тәкъдимнәрен көтеп калабыз, аларны чарада катнашырга чакырабыз.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# "...ИМАН БЕРЛӘ КОРЪӘН ТУЛГАН САДРЕМӘ!"

*(Тукай иҗатында дини мотивлар һәм борынгы әдәбият традицияләре)*

**Габдулла Тукай әсәрләре үз заманында ук зур уңыш казана. Кыска гына вакыт эчендә ул татар милләтенең сөеклесенә әверелә. Моның сәбәбе - шагыйрьнең күп гасырлык бай әдәби традицияләребезгә таянуында.**



Тукай урта гасырчылыктан яңа реалистик юнәлешкә борылыш чорында иҗат итте. Әдәбиятыбызга яңалыклар алып килүче реалист буларак танылса да, ул иҗатының бөтен тамырлары белән борынгы татар әдәбиятына, Көнчыгыш әдәбиятларына һәм тулаем Ислам мәдәниятенә, аның олы казанышларына - тарихи сюжетларына, мотивларына һәм форма-шәкелләренә тоташа, шулардан үсеп чыга. Кече яшьтән үк гади халыкның иң самими ышануларын, мәҗүсилек чорыннан ук килгән мифологиясен, соңрак мәдрәсәләрдә Ислам динен һәм аның риваятьләрен күңеленә сеңдереп, борынгы тарихы булган Ислам әдәбиятын укып үскән Тукай, иҗатында шуларны шигъри талантты, кодрәтле каләме аша үткәреп, элекке җирлектә, әмма яңа, югарырак дәрәҗәдә, үз заманына ярашлы һәм үзеннән соң да яшәячәк гүзәл әсәрләр тудыра алды.

Тукай иҗатында борынгы әдәбият мотивлары дигәндә, иң элек күз алдына Ислам мәдәниятенең бөек китабы Коръән күз алдына килә. Аллаһны бер вә бар дип белгән Тукайның Коръәнгә ихтирамы, мәхәббәте чиксез зур, ул Коръәнне укып әсәрләнә, юана, аннан үзенә чиксез илһам ала:

***Гомернең иң читен, җайсыз,***
***уңайсыз бер минутында,***
***Әгәр янсам каты хәсрәт вә***
***кайгының мин утында,***
***Укыйм тиз-тиз күңелдән***
***бер гаҗәип сүрә Коръәндин,***
***Газаплар мәгънәви бер***
***кул илән алынадыр җандин.***
***Оча дилдән бөтен***
***шик-шөбһәләр, һәм мин***
***җылый башлыйм:***
***Яңакларны мөкаддәс***
***күз яшемлә энҗели башлыйм...***

Заманында, XX йөзнең утызынчы елларында, социалистик реализм идеологлары "вак буржуаз шагыйрь" дип тамга салынган Тукайны, заманга яраштыру өчен, бөтенләй атеист ясарга көчәнеп караганнар иде. Ләкин аларның бармактан суырылган бу "атеистлыгы" Тукайның берничә шигъри юллары янында, комнан ясалган манара шикелле, ишелә дә төшә.

*(Дәвамы алдагы битләрдә.)*

# МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕ

**Без бүген җәмгыятебезнең рухи асылын торгызырга, яшәтергә, саклап калырга күп мөмкинчелек тудырылган заманда яшибез. Мамадыш мәдрәсәсенең максаты исә әлеге рухи мирасны саклап калу һәм аны киләчәк буыннарга ирештерү, шулай ук югары әхлаклы, дини һәм дөньяви белемнәр белән коралланган, җәмгыятебезнең төрле тармакларында хезмәт итә алырлык белгечләр әзерләү.**





Шунлыктан, уку-укыту программасы дини һәм дөньяви фәннәр катнашында төзелгән; укыту хәнәфи мәзһәбе буенча алып барыла. Дәрес программалары ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан расланган. Шәкертләргә мәдрәсәдә уку белән бергә, шәһәрнең һөнәри лицеенда да белем алу мөмкинлеге тудырылган. Мәдрәсәдә укулар көндезге бүлектә укучылар өчен 1 сентябрьдән, кичке бүлектә укучылар өчен 1 октябрьдән башлана.

Мәдрәсәнең тагын бер үзенчәлеге бар. Республикабыздагы башка мәдрәсәләрнең шәкертләр географиясе бик киң, аларга төрле төбәкләрдән килеп укыйлар. Мамадыш мәдрәсәсе җитәкчелеге исә район башлыгы киңәшен тотып, шәкертләрне катгый рәвештә үз районыннан гына туплый. Әлбәттә, шәкертләр туплауның мондый ысулы авырлыклар тудыра. Чөнки район күләмендә генә мәдрәсәдә укырга теләгән ихласлы укучыларны табу аерата авыр. Әмма әлеге принцип буенча хәрәкәт итү районны яшь дин белгечләре белән тәэмин итүдә уңай роль уйнамый калмый. Шәкертләр монда укый һәм яши башлау белән бер гаилә балалары сыман, бер-береңә ярдәм итеп, әдәпле һәм намуслы булып, берберсе турында кайгыртып-ярдәмләшеп яшиләр. Мәдрәсәдә уку-укыту алымнарын камилләштерү, укытучы-мөгаллимнәрнең педагогик осталыгын үстерү өстендә даими эш алып барыла, педагогик киңәшмәләрдә тәҗрибә уртаклашу була. Яхшы укучы шәкертләрнең олимпиадаларда катнашу мөмкинлеге булдырылган - мәдрәсә шәкертләре укудан буш вакытларын файдасыз үткәрми. Алар өчен һәрдаим төрле кызыклы чаралар үткәрелеп тора: спорт ярышлары һәм табигать кочагына чыгып ял итүләр гадәткә кертелгән, һәр уку елы башында Белем көне уздырыла, Коръән уку бәйгеләре үтә, сугыш ветераннары белән очрашулар, төрле әдәби кичәләр, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә булышу, мәктәпләрдә наркоманиягә каршы чыгышлар ясау - болар барысы да мәдрәсә тарафыннан үткәрелә торган чаралар. Шулай ук чыгарылыш кичәләре дә тирән эчтәлекле, истә калырлык итеп уздырыла. Шәкертләр һәм хезмәткәрләр өчен эчке тәртип кагыйдәләре эшләнгән. Шәкертләр алдына куелган ошбу таләпләр белән бергә, мәдрәсәнең эчендәге һәм аның тирә-ягындагы мәйдан чисталыгын - тәртибен дә әле алар үзләре сакларга тиешләр.

Мамадыш мәдрәсәсенең бүгенге көндәге мөдире - Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин. Ул 3 ел дәвамында Ислам дине кабул итүнең меңьеллыгы исемендәге мәдрәсәдә белем алган. Россия ислам университетын тәмамлаган, 4 ел Мисыр дәүләтенең әл-Әзһар университетында укыган. Параллель рәвештә Мәскәүдә читтән торып юридик факультет тәмамлаган. Мөдирнең ике ярдәмчесе бар. Уку-укыту эшләре буенча ярдәмчесе - Ранил хәзрәт Талипов. Ул Түбән Кама шәһәрендәге "Рисәлә" мәдрәсәсендә укыган. Ранил бүгенге көндә читтән торып Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институтында дөньяви белем үзләштерә. Тәрбия эшләре буенча ярдәмче - Ирек хәзрәт Нуриев. Ул РИУны тәмамлаган, хәзерге вакытта шул университетның магистратурасында укый. Мөгаллимнәр төркеме җиде кешедән тора. Аларның күбесе, дини белем белән бергә, дөньяви белемгә дә ия.

Башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, биредә укучы шәкертләр мәдрәсәдә генә укып калмыйлар - шәһәрнең 2 нче гимназиясендә дә белем алалар. Биредә алар машина йөртү хокукына таныклык алу өчен дә укыйлар. Әлеге шәкертләр өчен махсус расписание төзелгән, алар шимбә һәм ял көннәреннән тыш, өйләгә кадәр гимназиядә укып, өйлә намазыннан соң мәдрәсәдә гыйлем алалар. Тулы уку программасын үзләштергән укучыларга шәһадәтнамә тапшырыла.

Мәдрәсәнең ачылуына - 4 ел. 2011 елда мәдрәсәнең беренче чыгарылышы булды. Шул арада мәдрәсәнең кичке бүлеген сиксәнгә якын кеше тәмамлады. Шәкертләребезнең кайберсе мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, дини белемнәрен камилләштерүне дәвам иттереп, югары дини уку йортларына керә. Һәрхәлдә, биредә укып чыккан шәкертләрнең һәркайсы җәмгыятебезнең төрле тармакларында эшләп, милләтебезне, динебезне үстерүдә үзләреннән зур өлеш кертеп, үз халкыбызга хезмәт итәләр.

Әйтеп үтелгәнчә, мәдрәсәдә кичке уку бүлекләре дә эшли. Бу бүлеккә махсус урта һәм дөньяви уку йортларында югары белем алган яшьләр белән бергә өлкән яшьтәгеләр дә килә. Бу бүлектә укучылар арасында нинди генә һөнәр ияләре юк: табиблар, мәктәп укытучылары, төзүчеләр, журналистлар, игенчеләр, икътисад-сәнәгать өлкәсендә хезмәт куючылар һ.б. Укыту дәверендә, көндезге бүлектәге шикелле үк, бу бүлектә дә укытыла торган фәннәр буенча һәр сыйныфта да тикшерү эшләре, сыйныф эшләре һәм рефератлар языла һәм һәр уку елына зачёт-имтиханнар тапшырылып, алган белемнәр ныгытыла. Кичке бүлектә укыту ике төркемгә бүлеп алып барыла: эшләп укучы шәкертләр атнаның ике көнендә кичке якта, ә хезмәттә булмаганнар - атнаның ике көнендә иртәнге якта, ягъни өйләгә кадәр укыйлар. Ял көннәрендә оештырылган укулар кечерәк яшьтәге шәкертләр өчен. Мәдрәсәдә шулай ук имамнарның һәм абыстайларның белемнәрен арттыру курслары да эшләп килә. Алар айга бер тапкыр мәдрәсәдә белемнәрен арттыралар. Елга өч мәртәбә унар көнлек курслар да оештырылган. Мәдрәсәдә укып чыгып шәһадәтнамәләр алган укучыларга да биредә гыйлемнәрен тагын да камилләштерү өчен мөмкинлекләр тудырылган. Алар атнага бер тапкыр мәдрәсәгә килеп укып китә алалар.

Мамадыш мәдрәсәсе базасында балалар лагерьлары да үткәрелә. Шунысы үзенчәлекле, мәдрәсә мондый лагерьларны елның дүрт фасылында да үткәрергә тырыша. Бу чаралар мәктәп балаларының каникул вакытына туры китереп эшләнелә. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, мондый лагерьларда балалар урамның тискәре йогынтысыннан арыналар, рәхәтләнеп ял итәләр, сәламәтлекләрен ныгыталар, дини белем һәм тәрбия алалар, тәртипкә, олыларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр. Алар арасында дуслык мөнәсәбәтләре һәм бер-береңә мәрхәмәтлелек хисе урнаша. Бу балаларның алдагы тормышларын күзәтсәк, аларның күбесе тормышта ныклы позициядә тора, прогрессив фикер йөртә һәм дини белемнәрен югары уку йортларында укыган чакта дәвам иттерә.

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# "...ИМАН БЕРЛӘ КОРЪӘН

Менә 1909 елда язылган "Васыятем" исемле шигыреннән түбәндәге юлларны укып китик:

***Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен,***
***күреп актык сүзем:***
***Күр, нә рәсмә тулган Иман***
***берлә Коръән садремә!***

Садренә, ягъни күңеленә Коръән урнашкан шагыйрь андагы илаһи аятьләрне шигъри юллар белән чын татарча әйтеп бирергә омтыла.

Коръәннән кергән сюжетлар, мотивлар, персонажлар аның иҗатында зур урын алган. Ә инде аерым шигырьләре тулаем Коръән аятьләренә багышланган.

***Ярты төн булган чагында,***
***китте Мәккә ялтырап:***
***Нур тоташты җиргә күктән,***
***иңде нурдан бер Пырак.***
***Хазрәти Җибрил бәшарәт әйләде, дип:***
***"Йа Рәсүл!***
***Хак Тәгалә хазрәте тәгъйинләде***
***бу кич вөсул.***
***Мөнтәзыйрлар, лә мөкәнләр,***
***бар мәләикләр сиңа,***
***Гарше әгълә килде, атлансаң,***
***аягың астына", -***

дип башланган "Мигъраҗ" шигыре Коръәни-Кәримдәге 17 нче сүрә нигезендә язылган һәм башка китаплардагы риваятьләрне кабатлаган. Татар әдәбиятында Мигъраҗ, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Иерусалимга сәфәре, әл-Әкъса мәчете гөмбәзеннән күккә ашуы турындагы бу популяр сюжет Рабгузыйның "Кыйссасел әнбия"сеннән (1311), Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел фәрадис"еннән (1358) башлап, XX йөз башына кадәр дистәләрчә әсәрләрдә кабатланган. Кечкенәдән үк пәйгамбәрләр тарихын укып үскән Тукайны бу сюжет юкка гына илһамландырмаган, билгеле.

Шагыйрьнең "Кадер кич" дип исемләнгән әсәре дә турыдан-туры Коръәнгә барып тоташа. Ул андагы "Кадер" дип аталган 97 нче сүрәне шагыйранә тасвирлап биргән. Шагыйрь күңел күтәренкелеге, тирән ышаныч, пафос, матур, җиңел тел белән бу кичәне бер монументаль картина итеп сурәтли. Шигырьнең язылу тарихын композитор Мансур Мозаффаров түбәндәгечә аңлата: "Бервакыт әнием Тукайдан: "Менә Кадер киче җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы икән синдә, Габдулла?" - дип сорады. Тукай берничә көннән безгә "Бу Кадер кич - елда бер кич..." дип башлана торган шигырен, үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка алып килде".

Гомеренең соңгы көннәрендә, Клячкин хастаханәсендә ятканда да шагыйрьнең күңеленнән Коръән сүзләре туктап тормый. Менә аның иң соңгы әсәрләреннән булган "Тәфсирме? Тәрҗемәме?" дип аталган шигыре:

***Һәр заман, кем насры берлән***
***фәтхе килсә, Алланың -***
***Һич тә бер көч туктаталмый,***
***манигы булмый аның.***
***Син күререң тугры юл***
***тотканны күп төркем халык,***
***Хәмд-ү-тәсбих өннәре берлән***
***гөрелдәр урталык.***
***Мәккәдә ачты бүген якты иманга***
***баб Ходай,***
***Ярлыкау эстә, шөкер ит,***
***тәүбә кыл, тәүваб Ходай!***

Бу - Коръәни-Кәримнең "Насыр (Ярдәм)" дип аталган 110 нчы сүрәсе. Аның гарәпчәдән татарчага сүзгә-сүз тәрҗемәсе болай: "Аллаһның ярдәме һәм җиңүе ирешкәндә, син кешеләрнең ничек төркем-төркем булып Аллаһның диненә керүләрен күрдең; шулай булгач, үзеңнең Раббыңны макта, данла һәм аннан тәүбә сора. Дөрестән дә, Ул - ярлыкаучы!" Күргәнебезчә, Тукайның бу шигыре шушы атаклы сүрәнең шактый ук төгәл тәрҗемәсе. Шул ук вакытта, бу - тәрҗемә генә түгел, чөнки анда шагыйрьнең өстәмәләре, аңлатмалары да кереп киткән. Мәсәлән: "Һич тә бер көч туктаталмый, манигы (киртәсе) булмый аның", һәм "Мәккәдә ачты бүген якты иманга баб (ишек) Ходай" дигән юллар Тукайның үз сүзләре, үз тәфсире. Шуңа күрәдер дә, ул бераз шикләнептер, ахры, шигыренең өстенә "Тәфсирме? Тәрҗемәме?" дип язып куйган. Шагыйрь исән булса, бәлки, бу әсәрен яңадан карап чыгып, китап итеп бастырганда башка исем куйган булыр иде. Әмма инде бу - үлеме алдыннан язган соңгы шигырьләренең берсен җыентыкта басылып чыгуын күрергә Тукайга насыйп булмаган. Ул "Аң" журналының 1913 ел, 7 март санында чыккан нөсхәсен генә күрсә күреп калгандыр...

Коръәндә телгә алынган пәйгамбәрләр, алар белән бәйле риваятьләр, ул вакыйгаларда катнашкан төрле персонажлар Тукай шигырьләренә бик табигый кереп, тыгыз үре-

# Мөхәммәд галәйһиссәламнең үз кулыннан...

**Беренче тапкыр безнең бабаларыбыз ислам дине белән Азов буе Бөек Болгарда, Хәзәр каганлыгында таныша. Шунда ук шактый өлеше ислам динен кабул итә. Безнең якларга килгән болгарларның, дөресрәге, салты-маяк археологик культурасына караган кабиләләрнең шактые ислам динендә була инде.**

Кайбер чыганаклар Азов буе болгарларының Мөхәммәд пәйгамбәр вакытында ук ислам динен кабул итүләре хакында сөйли. Шундыйлардан Чокрыкчызадә исеме белән мәшһүр булган XVI-XVII йөз язучысы Мөхәммәд бине Мөхәммәднең "Алты бармак китабы" (яисә "Дәлаилел-нөбүвәт" - Пәйгамбәр дәлилләре). Бу күләмле китап инкыйлабка кадәр төрки-татарлар арасында иң популяр әсәрләрдән саналган. Берничә тапкыр Казанда басылып чыккан (1899, 1905, 1910 һ.б. елларда). Монда (570-633 еллар) бөтен могҗизалары, төшләре белән Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы тасвирлана. Әсәр алты кисәктән тора. Мөгаен, шуңа күрәдер дә, "Алты бармак" дип атала. Моннан тыш, һәр кисәк тагын ваграк бабларга бүленә. Һәр баб Мөхәммәд пәйгамбәрнең аерым елдагы гамәлләренә багышланган. Һижри белән 7 нче (милади белән 629) елда башка хәлләр белән беррәттән түбәндәге вакыйга да хикәяләнә. Бу чыганакка безнең игътибарны язучы һәм галим Фәрит Яхин юнәлдерде. Хикәят беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелгәнлектән, аңа тулырак тукталыйк.

Хәзерге телгә тәрҗемәсе: "Фәруһ бине Гамру Хизамигә Рум падишаһы тарафыннан Болгар җиреннән Гоман хан иде. Мөселман булды. Вә пәйгамбәр салаллаһу галәйһи вәссәламгә хат биреп үзенең буйсынганнарыннан Мәсгуд бине Сәгыд исемле кеше кулы белән ничә бүләк бәрабәренә күндерде. Мәдинәгә килеп хатын рәсүл салаллаһу тәгалә галәйһи вәссәламдә мәҗлесендә укыдылар. Язылган: "Бу хат хәзрәте пәйгамбәр салаллаһу тәгалә вәссаләмгә Фәруһтан белдерү - мин иманга килдем. Аллаһы Тәгаләнең вәгъдә-ниятенә һәм синең пәйгамбәрлегеңә карар итәм. Мин беләм, син шул пәйгамбәр Гайсә галәйһиссәлам синең киләчәгең турында белдерде". Хәзрәт (Мөхәммәд пәйгамбәр. - Г.Д.) килгән кешене зурлады. Билалга кунак буларак кабул итәргә әмер бирде. Бүләген кабул итте. Әйтерләр: бер ак ат һәм алтын белән тукылган бер яхшы кафтан, тагын берничә әйбер бүләк итте. Атны Әбу Бәкергә багышлады. Кафтанны Мәхәррәмәд бине Нуфалга бирде. Бер ат, бер ишәк бар иде. Аларны Сәгыд Сәгъдигә бирде. Шуннан соң күзәдә (балчыктан яндырып эшләнгән савыт, чүлмәк? - Г.Д.) һәм энҗе савытлары бар иде. Хатыннарына өләште. Хатның җавабында язды: "Мөхәммәд рәсуллаһтан Фәруһка язылды. Әмма шулай итеп, җибәрелгәннәр (хат, бүләкләр) безгә килеп иреште. Вә исламыңнан хәбәр бирдең: син хакыйкатьтә, Хак Тәгаләң сине тугры юлга дәлил итте. Биш вакыт намазны кылып, вә зәкятеңне үтәрсең". Вә Билалга әмер бирде. Ул Мәсгудкә 500 дирһәм акча биреп, вилаятенә кире кайтарып җибәрде.

Хәбәр ителер: Фәруһның исламының хәбәре Рум падишасына иреште. Фәруһны чакыртып, әйтте: "Мөхәммәд диненнән кайт. Сиңа ничә мәмләкәт бирим. Фәруһ әйтте: "Кайтмыйм, чөнки мин беләм, хак пәйгамбәрдер (Мөхәммәд галәйһиссәләм. - Г.Д.). Шулай ук син дә тагын бел, Гайсә бине Мәрьям галәйһүма әссаләм килмәс борын хәбәр биргән пәйгамбәрдер. Ләкин милкеңнән һәм мәмләкәтеңнән аерылабыз. Сине хактан кире кагар. Аннан Рум падишаһы аны тоткын итте. Ничә вакыттан соң җәзалап, мәетен дар агачына асты. Рәхмәтуллаһу галәйһи".

Кыскасы, шулай итеп, болгарлар хакиме Фәруһ бине Гамру Хизами ислам динен кабул итә. Моны рәсмиләштерү өчен Мәдинәгә 629 елны Мөхәммәд пәйгамбәргә үзенә буйсынган Мәсгуд бине Сәгыдне хат һәм бүләкләр биреп илче итеп җибәрә. Мөхәммәд пәйгамбәр Болгар хакиме һәм болгарларның ислам динен кабул итүләренә хәерфатихасын бирә. Моны ишетеп, Византия императоры болгарлар хакименә ислам диненнән күп мәмләкәтләр бирү бәрабәренә баш тартырга чакыра. Фәруһ бу таләпне үтәмәгәч, император аны җәзалап үтерттерә.



Бу хикәят легендар характерда. Кайчандыр ислам динен кабул иткән халыкларның мөселманлыкны Мөхәммәд пәйгамбәрнең үз кулыннан алынуын расларга омтылган легендар хикәятләре аз булмаган. Шулай да болгарлар белән бәйләнешле бу хикәят үзенең реаль тарихка якынлыгы белән игътибарны җәлеп итә.

VII гасырда хикәяттәге "Рум тарафында болгарлар җире", шиксез, Азов буе Бөек Болгар дәүләте урнашкан яки, гомумән, болгар кабиләләре яшәгән җирләр. Бу чорда, чыннан да, Византия яки Көнчыгыш Рим империясе кодрәтле һәм гаять зур дәүләт була. Ул көнбатыштан көнчыгышка таба 4300 километрга сузыла: Балкан, Кече Азия, Сүрия-Палестина, Мисыр, Төньяк Африканың диңгез буе, Пирәнәй ярымутравының көньяк-көнчыгыш өлеше. Урта җир диңгезендә Византия флоты хакимлек итә. Чыганакларга караганда, болгар-грек мөнәсәбәтләре аеруча император Ираклий вакытында (яшәү еллары 575-641, идарә итү еллары 610-641) көчле була. Хикәяттә сөйләнгән "Рум падишаһы" (629 ел) аның идарә итү елларына туры килә. Грек-византия культурасының тәэсире "Кубрат хан хәзинәсе" дип аталган табылдык әйберләрдә дә үзен бик нык сиздерә. Шушы вакытта (VI гасырның егерменче елларының ахыры - VII йөзнең утызынчы еллар башы) Азов, Кара диңгез, Кубань буйларында Бөек Болгар дәүләте оеша. Бу дәүләт берләшмәләренең иң күренекле ханнары - Орган һәм Кубрат. Яңа оешып килгән дәүләт буларак, монотеистик диннәргә игътибар юнәлтелә. Христиан дине белән яшь ислам дине мәнфәгатьләре бәрелешә. Вакыты-вакыты белән Болгар Византиягә күпмедер дәрәҗәдә буйсынган кебек тәэсир кала. Византия болгарлар арасында христиан динен тарату эшен алып бара. Кайчак ул өлешчә уңышка да ирешә. Чыганакларда хәтта ил башлыклары Орган яки Кубратның христиан динен иман итүләре хакында да хәбәрләр теркәлгән. Шуңа күрә дә үз вассалының ислам динен кабул итүе Византия императорында шулхәтле ярсу тудыра ки, хәтта, югарыда китерелгән чыганактан аңлашылганча, ул җәзалап үтерелә. Өлешчә гарәпләр яшәгән җирне дә биләгән Византия тиз арада хәлиф Мөхәммәд тарафдарлары белән кискен бәрелешкә керә. Гарәпләр 640 нчы елларда ук Константинопольне камап торалар, Византия империясенең күп җирләрен яулап алалар.

Шул рәвешле "Алты бармак"та китерелгән вакыйга ул чордагы тарихи мохиткә бик тә туры килә. Әмма бу чорда, мөгаен, ислам тотрыклы дингә әверелә алмагандыр әле. Ул яңадан хәзәр-гарәп сугышлары вакытында көчәя. Бу вакытта инде Бөек Болгар дәүләте таркалып, Хәзәр каганлыгына кушылган була.

737 елда гарәпләр Мәрван җитәкчелегендә Хәзәр башкаласын алгач, каганга һәм ил халкына ислам диненә керергә тәкъдим итәләр. Шулай да ул чорда әле ислам Урта Азиядә һәм Кавказ артында яңа гына таралганга күрә, әллә ни уңышка ирешә алмый. Шулай да, Харәземнән чыккан мөселманнар монда аз булмый. Әмма хикмәт мөселманнарның азлыгында яки күплегендә генә түгел, аларның ил эчендә тоткан урыннарында. Алар каган гвардиясенең төп өлешен тәшкил итә. Харәзем мөселманнарының шактый булуы бу якларда Урта Азиягә хас ислам диненең таралышына китерә һәм киләчәктә Урта Идел һәм Кама буйларында да шул рухтагы исламның үтеп керүенә бер сәбәп була. X гасыр башында Итиль шәһәрендә мөселманнар шактый күп яши. Хәтта каган бәкнең вәзире, ягъни беренче кешесенең мөселман булуы мәҗбүри итеп куела. Итил X гасыр урталарында берничә сәүдә кәрван юлының кисешкән урынына әверелә. Бу сәүдәдә Харәзем, Дәрбәнд, Хорасан һәм ерак Һиндстан, Кытай, Йәмән белән тыгыз элемтәдә булган мөселман сәүдәгәрләре зур роль уйный. Хәзәр-болгарларда ислам диненең киң таралышы әл-Куфи, әл-Белазури кебек гарәп язма чыганакларында гына түгел, археологик эзләнүләр нәтиҗәләре белән дә исбатлана. Бу якларда археологлар тарафыннан казып тикшерелгән, болгар-хәзәрләргә нисбәтле күп кенә каберләрнең мөселман йолаларын үтәп күмелүе билгеле булды (К.И. Красильников һ.б.). Нумизмат Ә.Г. Мөхәммәдиевның тикшеренүләренә караганда, Хәзәр каганлыгында куфи мөселман акчаларының күпләп сугылуы да ислам диненең ныклап таралуы хакында сөйли.

Мәскәү галиме А.П. Новосельцев нигезләгәнчә, хәзәр-болгарлар X гасыр ахырында Харәземнән яңадан рәсми рәвештә ислам динен кабул итәләр.

Идел, Кама буйларында яңа дәүләтләрен төзегән болгарлар бу чорлардан да бай рухи мирас алалар. Алай гына түгел, болгарларның киләчәктә халык дине дә, дәүләт дине дә итеп ислам динен алулары, нигездә, шул чорларда ук билгеләнгән була.

Шулай итеп, югарыда китерелгәннәрдән чыгып фикер йөрткәндә, безнең ерак бабаларыбыз ислам динен Мөхәммәд галәйһиссәламнең үз кулыннан, аның турыдан-туры хәер-фатихасы белән кабул итүләре ачыклана.

**Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН,**
**Казан (Идел буе) федераль университетының**
**Тарих институты профессоры,**
**тарих фәннәре докторы**

# ТУЛГАН САДРЕМӘ!"

леп баралар, шагыйрьнең әйтәсе килгән фикерен үтемлерәк итеп бирергә ярдәм итәләр. Чөнки ул заманның дин тоткан, аның тиешле кагыйдәләрен үтәп барган, Коръәнне, әдәбиятны яхшы белгән кешесенә болар барысы да бик якын, аңлаешлы булган.

***Пәйгамбәрнең вафатыннан***
***соң аслан могҗиза булмас:***
***Ярылмас ай икегә,***
***һәм кара таштан дөя тугмас, -***
***Диләр безнең гыйлем әһле.***
***- Ышанмагыз, бу ялгандыр;***
***Үзем күрдем бүген,***
***безнең заманда могҗиза бардыр:***
***Бүген иртүк миңа шактый***
***бурычлы иптәшем килде,***
***Ялындырмый, талашмый,***
***вәгъдәсендә акчасын бирде.***

**("Могҗиза")**

Хәзерге заман укучысы бу юмористик шигырьдәге "ярылмас ай икегә", "кара таштан дөя тугмас" дигән сүзләргә артык әһәмият бирмичә генә узып китә. Ә Коръәнне һәм дини мифологияне белгән кешегә бу гыйбарәләр күп нәрсә аңлата. Риваять буенча, кяферләр Мөхәммәд пәйгамбәрне җирдәге могҗизаларына ышанмыйча, аны "сихерче" дип атап, аннан күктә могҗиза күрсәтүен, мәсәлән, үз кодрәте белән айны икегә ярып, ике кисәген ике якка җибәрүен, аннары аларны ике җиң очыннан чыгарып, үзенә сәҗдә иттерүен сорыйлар. Мөхәммәд исә моны үтәп чыга. Тукай менә шуңа ишарәли.

Тәэсир көчен арттыру, күренешләрне җанландырып, көчәйтеп җибәрү өчен Тукай еш кына мифологик мотивларны да куллана. Табигать күренешләрен тасвир иткәндә дә бу мотивлар бик табигый рәвештә әсәр тукымасына үрелеп китәләр.

***Кисәктән җанланып, бозлар агалар;***
***Чабалар, берсене берсе кагалар.***
***Белерсең син боларның мәхшәре дип,***
***Бу бозларны - үлекләр гаскәре дип;***
***Өрелмеш дип белерсең, санки, мөгез***
***Вә яки мөгезен селкеткән үгез.***
***Болар әллә бара дәһшәтле судка,***
***Беленми: кайсы - җәннәт, кайсы - утка.***

**("Яз")**

"Бәдәвам", "Ахырзаман", "Нәһҗел фәрадис" китапларында сурәтләнгән, һәр татар укучысында балачактан таныш булган, күңелләрдә курку хисе уяткан Кыямәт көне, бар мәрхүмнәрнең терелеп, бер урынга җыйналулары, ягъни мәхшәр, Исрафил фәрештә быргысының бөтен дөньяны тетрәткән авазы, җәннәт һәм тәмуг картиналарын күз алдына китереп, Тукай гади генә бер табигать күренешен дә кешене әсәрләндерерлек итеп тасвирлап бирә.

Шагыйрь татарның элек-электән укылган, балачактан ук хәтеренә сеңгән борынгы классик әдәбиятына, урта гасырларның дини әсәрләренә еш мөрәҗәгать итә. "Кыйссаи Йосыф", Рабгузыйның "Кыйссасел-әнбия"се, Хуҗа Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Суфи Аллаһияр шигырьләре һәм бигрәк тә "Мөхәммәдия", "Бакырган"нан алынган мотивлар Тукайда еш очрый. Шагыйрь һәммә татарга таныш, сөеп укылган шигырьләрнең үлчәмен, көен, рифмаларын алып, аерым сүзләрен кабатлап, бөтенләй яңа әсәрләр - Тукайның үз чоры кешеләрен, тормыш картиналарын, заман проблемаларын сурәтли торган, бөтенләй көтелмәгәнчә яңгырашлы әсәрләр иҗат итә.

Тукайның борынгы әдәбиятыбыздан зур бер язма дастан алып, андагы сюжетны, шигырь үлчәмен, тәгъбирләрне тулысынча үз максатында кулланып иҗат иткән зур әсәре бар. Бу - "Печән базары яхуд яңа Кисекбаш" поэмасы. Шагыйрь бу очракта XIV йөзнең героик дастаны "Кисекбаш"ны бөтенләй икенче характердагы, сатирик пландагы әсәре өчен бик уңышлы куллана. Борынгы җитди, героик "Кисекбаш" фонында Тукай заманының татар тормышы үтә вак, кызганыч һәм көлке тоела. Иске "Кисекбаш"ны яхшы белгән шул заман татар укучысында Тукайның "Кисекбаш"ы гаҗәеп тәэсирләр уята, һушын ала, шаккатыра, заманның бөтен борчулы проблемаларын татар аңына тагын да калкытыбрак, үтемлерәк итеп җиткерә.

Менә шулай борынгы әдәбиятыбыз традицияләренә нык таянып иҗат иткәнгә күрәдер инде, Тукайның замандашлары Зәки Вәлиди һәм Галимҗан Ибраһимов, аның иҗатына бәя биргәндә, әсәрдә әлләни яңалык күрмиләр. Тукайга караганда югарырак белем алган, рус һәм Европа әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белгән, күп укыган бу зыялыларның, бәлки, Тукайның шул замандагы рус, француз, алман шагыйрьләре кебек язуын күрәселәре килгәндер. Ләкин Тукай алар теләгәнчә - Көнбатыш әдәбиятчыларына ияреп язган булса, аның иҗаты күпчелек халык тарафыннан яратып, якын итеп һәм аңлап кабул ителмәс иде, минемчә.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Ничек конфликтларсыз аралашырга?

**Безнең һәрберебезнең дә үз тормышында кемнәрнеңдер кызып киткән, кычкырыш, ызгыш-талаш шаһите, ә кайбер очракларда катнашучысы да булырга туры килгәне бардыр. Кем белән булса да сүзгә килешеп алганнан соң, без булган хәлләрне бәяләү, аңа нәтиҗәләр ясый башлавыбыз сирәк түгел.**

Кайчагында "әйткәләгәннәреңә" үкенергә туры килә, шәхси дөреслегеңдә шикләнүләр туа, әмма... и-их, мөнәсәбәтләр бозылган. Нәкъ менә шундый минутларда конфликтлардан нинди юллар белән котылырга, аны ничекләр итеп булдырмый калырга мөмкин иде соң дип уйлана башлыйсың.

Ә барыннан да үкенечлесе шунда: конфликттан ничек качасын да беләсең кебек, альтернативаларны да карыйсың, әмма, чынлыкта, мәсьәлә хәл ителми, бердәм мантыйк чылбыры хасил булмый. Моннан тыш, ни генә була калган очракта да, игътибар үзәгенә алынган мөһим тормыш мәсләген саклап калырга кирәк булган очраклар да була бит әле...



Ә хәзер күз алдына китерегез: сезнең конфликтны үстерүгә юл куймыйча, аны булдырмый калу чарасын алдан ук күрү мөмкинлегегез бар иде, ди. Бик күпләр, бик теләп, мондый мөмкинлекне файдалана ала. Төп мәсьәлә бары шунда гына: моңа ничек ирешергә?

Иң башта барлык мөмкинлекләрне файдалануга бәйле булган гап-гади хакыйкатьне истә тотарга кирәк булачак. Беренче карашны болайрак тәгъбирләргә мөмкин: "Әгәр дә сез низаглашырга исәп тотмыйсыз икән, сезнең белән тиргәшеп булмаячак". Үзләштерергә кирәк булган икенче кагыйдә болайрак яңгырый: "Конфликтны тулаем тискәре күренеш кенә итеп карарга ярамый, күп очракта ул уңай нәтиҗәгә алып килә, ә иң мөһиме - аны дошманлык дәрәҗәсенә җиткермәскә кирәк".

Көнкүрештә һәм тормышта була торган сүзләшүләрне булдырмый калырга өйрәнү өчен, аның җәелергә мөмкин үсешен (динамикасын), схемасын аңлау мәслихәт. Нинди генә очракта да каршылыклар җыелмасы оеша - ул нинди дә булса ихтыяҗны канәгатьләндерүдә куркыныч тудыра торган көч. Каршылыклар җыелмасы сыйфатында һәрьяк өчен алдан уйлап куелган нинди дә булса соңгы максат булырга мөмкин. Әлеге максатка дәгъва итүчеләр ким дигәндә икәү булса яки һәрбер билгеле бер (конкрет) кешенең аңына соңгы максат төрлечә күзалланган вакытта ызгыш-талаш барлыкка киләчәк тә инде.

Әгәр дә үз алдыңа ызгыш-талашта җиңүне максат итеп куймыйча, теләктәшлеккә ирешүне хуплыйсың икән, конфликттан нәкъ менә шушы сәбәп буенча җиңел генә котылырга мөмкин. Әлеге бурыч-вазифаны тормышка ашыру өчен, барыннан да бигрәк, сезнең оппонентта кайсы омтылыш өстенлек алганлыгын ачыкларга кирәк. Ызгыш-талаш әдәбендә өч төп омтылыш-максатны аерып чыгарырга мөмкин.

Беренчесе - ул шәхси фикереңне белдерү. Билгеле булганча, шәхси фикер шәхеснең мөстәкыйльлеген гәүдәләндерү чарасы булып хезмәт итә, һәм, аны узып китеп, кеше бик күп чикләр аша күчеш ясарга мөмкин. Мондый кеше аның фикерен үзгәртә алырлык фикер, эшгамәл юклыгын расларга керешәчәк. Мөгаен, моңа охшаш очракларда конструктив диалог мөмкин түгел, ул баштан ук уңышсызлыкка дучар була. Бу мизгелдә үз-үзеңне тоту кагыйдәсе чын карашыңны тулысынча ачу мөмкинлегенә бер адым булачак. Сез бу кешенең фикерен хөрмәт итәсез, аның белән килешәсез дә диярлек, тик кайбер шәхси сорауларда гына фикерләрегез аерыла икәнлекне аңа төшендерә башлау бик тә мөһим. Мондый очракларда аралашуның иң кулай рәвеше булып әңгәмәнең түбәндәге схема буенча оештырылуы мөһим: "Мин сезне һәм әлеге мәсьәлә буенча сезнең фикерегезне бик тә яхшы аңлыйм; минем төгәллек кертәсе килгән бер караш шул гына..." - һәм моңа охшаш чыгыштан соң төп мәсьәлә буенча фикер алыша башларга мөмкин. Барыннан да бигрәк, әңгәмәдәшеңнең дөрес түгеллеген ашыгып исбатларга тырышмагыз, моның белән сез аны үзегезгә һәм үзегезнең фикерегезгә каршы тагын да ныграк этәрәчәксез. Иң яхшысы - үз тәкъдимнәреңне "Мин моны менә шулай дип уйлыйм" кебек катгый раслау дәрәҗәсендә түгел, бәлки "Әгәр без моңа бераз башкачарак карасак?" соравы рәвешендә тәкъдим итәргә. Иң әһәмиятле һәм иң катлаулы вазифа - оппонентыгызның соңгы карары, сезгә бәйле булмаган кебек, гүя аның үзе уйлаган фикере буларак оешкан карар юнәлешендә әңгәмә куерту осталыгы. Шунысын да истә тотыгыз, бәхәстә беркем дә үз фикерләренең кире кагылуын теләми. Әгәр дә сез, хәтта бәхәсләшергә урын калдырмый торган дәлилләр китерәсез икән, үз оппонентыгызны почмакка куып кертеп һәм шәхси дөреслегегезне исбатлап җиңүгә ирешәсез икән, сезнең әңгәмәдәшегез барыбер үзен бик үк уңай хис итмәячәк һәм киләчәктә сезнең белән аралашмаска тырышачак, ә бу исә шулай ук бик үк өметле киләчәк түгел.

Икенче омтылыш-максат - бу шәхси ихтыяҗ һәм иҗтимагый канун-кагыйдә конфликты. Бу тип кешеләр өчен гомум кабул ителгән караш-гадәтләрне чын мәгънәсендә юкка чыгару әһәмиятле. Күрәсең, мондый кешеләр өчен бәхәс үз-үзен күрсәтү чарасыннан тыш бернәрсә дә түгел. Гадәттә, бу күренеш халыкта бар нәрсәне дә тулысынча кире кагу, танымау (нигилизм) дип йөртелә. Мондый тип кешеләр белән үзара аралашу рәвеше алдагысы белән охшаш; бу очракта шәхси хис-тойгыдагы өстенлекнең әһәмияте бик нык көчәеп китә. Шунысын истә тотарга кирәк: моңа охшаш нигилизм битлеге, барыннан да элек, яклаучысы (таянычы) булмаган һәм психологик яктан зәгыйфь кешеләргә хас.

Омтылыш-максатның өченчесе - иҗтимагый кысалар (социаль нормалар) системасындагы конфликтлар белән бәйле. Әлеге очракта төрле карашлар, инанулар, әхлак (мораль) кагыйдәләренең "бәрелешүе" игътибар үзәгеннән китми. Мондый чакта барысы да үзеңне башка берәү урынына куеп карау мөмкинлеге һәм вакыйгаларны башка шәхес күзлегеннән бәяли белү әңгәмәләре оештыру хисабына хәл ителә.

**(Ахыры газетабызның киләсе санында.)**

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕ

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Мәдрәсәнең киләчәккә дә планнары зурдан. Шәкертләргә аерым бинада торак булдыру, аерым ашханә, мунча төзү, яшелчә саклый торган склад булдыру, барлык уку классларын интерактив такталар белән һәм кирәкле әсбаплар белән җиһазлау, үз-үзен финанс яктан бәйсез итәрлек җитештерү тармагын эшләтеп җибәрү: үз умарталыгын булдыру; газета-журналлар, китап-брошюралар бастыру өчен типография сатып алу; үз машина паркын ачу. Укыту программаларына килгәндә, дини юнәлештән тыш, шәкерләрне профильле һөнәр белгечлекләре буенча укыту һ.б. Бу эшләр күп хезмәт таләп итә, әмма Аллаһның рәхмәте зур. Сәбәбенә керешергә генә кирәк.

Әлбәттә, мәдрәсә эшчәнлегендә четерекле мәсьәләләр дә юк түгел. Алар арасында иң авыры - финанс мәсьәләсе. Биредә мөгаллимнәр аерата аз хезмәт хакы алып эшли. Күбесенең гаиләсе, балалары бар. Аларга көне буе мәдрәсәдә бил бөгәргә туры килә. Шунлыктан, бүтән өстәмә керем чыганагы эзләргә вакытлары да калмый. Проблеманың икенче ягы да бар. Акча аз түләнгәч, тиешле белгечлеккә һәм квалификациягә ия булган белемне кадрларны җәлеп итү дә мөмкин түгел. Шуңа күрә тиешле финанс базасыз сыйфатлы белем бирү турында сүз алып бару файдасыз. Шәкертләрнең тору урыннарын, дәресханәләрне, ашханәне тиешле дәрәҗәдә тоту, шәкертләрне көн саен ашатуэчертү, дәреслекләр һ.б. әсбаплар белән тәэмин итү, әлбәттә, чыгымнар дигән сүз... Әлегә мәдрәсә динебез турында кайгыртучы милләттәшләребез, милләтпәрвәр шәхесләребез, иманын җуймаган мәхәллә халкы һәм район хакимияте даирәсендә эшләүче җитәкчеләребез ярдәмендә көн күрә. Аларга Аллаһ Раббыбыз һәр ике дөньяның бәхетсәгадәтенә ирешергә насыйп әйләсә иде.

***Фотолар мәдрәсә архивыннан.***
***Габдрахман ХӘБИБУЛЛИН,***
***Мамадыш мәдрәсәсе мөдире***

# "...ИМАН БЕРЛӘ КОРЪӘН ТУЛГАН САДРЕМӘ!"

*(Ахыры. Башы 1-3 нче битләрдә.)*

Бигрәк тә татар дөньясы ничәмә еллар буе килгән уртагасырчылык традицияләреннән яңалыкка, реализмга әле яңа гына борылган чакта андый әсәрләр халыкка ят тоелыр иде, чөнки һәрбер яңалыкны кабул итү өчен мәгълүм бер әзерлек кирәк. Тукайның реализмы - үзе зур бер яңалык. Замандашларының шигырьнең яңалыгын күреп бетермәүләре дә гаҗәп түгел, чөнки зур вакыйга ерактанрак, еллар үткәч яхшырак күренә. Тукайның иҗаты борынгы әдәби мирастан һич аерылгысыз, аның шигырьләре шуңа күрә дә бик халыкчан, вакыт сынауларын җиңеп үтә торган үлемсез әсәрләр. Шагыйрьнең бөеклеге дә шунда.

***Нәҗип НӘККАШ (ИСМӘГЫЙЛЕВ),***
***Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре,***
***Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе***




ООО «Ритуальные услуги»
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

Реклама


## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 28.04.12 | **3:37** | **5:07** | **13:02** | **17:51** | **20:16** | **21:46** |
| *Якшәмбе* | 29.04.12 | **3:34** | **5:04** | **13:02** | **17:53** | **20:18** | **21:48** |
| *Дүшәмбе* | 30.04.12 | **3:32** | **5:02** | **13:02** | **17:54** | **20:20** | **21:50** |
| *Сишәмбе* | 1.05.12 | **3:30** | **5:00** | **13:02** | **17:55** | **20:22** | **21:52** |
| *Чәршәмбе* | 2.05.12 | **3:28** | **4:58** | **13:02** | **17:57** | **20:24** | **21:54** |
| *Пәнҗешәмбе* | 3.05.12 | **3:25** | **4:55** | **13:02** | **17:58** | **20:26** | **21:56** |
| *Җомга* | 4.05.12 | **3:23** | **4:53** | **13:02** | **17:59** | **20:28** | **21:58** |
| *Шимбә* | 5.05.12 | **3:21** | **4:51** | **13:02** | **18:01** | **20:30** | **22:00** |


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №17 (134) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-531.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 26 апрель көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**